ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

«Татарстан Республикасы территориясендә салым салуның патент системасын кертү турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 135-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары К.Ә. Ногаев, А.Ф. Сафин тарафыннан кертелгән «Татарстан Республикасы территориясендә салым салуның патент системасын кертү турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 135-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре
2025 елның 24 декабре
№ 491-VII ДС

Проект

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы депутатлары
К.Ә. Ногаев,
А.Ф. Сафин
тарафыннан кертелә

**«Татарстан Республикасы территориясендә салым салуның патент системасын кертү турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында»**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

**1 статья**

«Татарстан Республикасы территориясендә салым салуның патент системасын кертү турында» 2012 елның 29 сентябрендәге 65-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (2020 елның 25 декабрендәге 90-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2012, № 9; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2021, № 1 (I өлеш), № 36 (I өлеш); 2022, № 77 (I өлеш); 2023, № 73 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2 статьяның 1 өлешендәге 44 пунктын үз көчен югалткан дип танырга;

2) 3 статьяның 2 өлешендәге беренче абзацында «34 – 44» саннарын «34 – 43» саннарына алмаштырырга;

3) 4 статьяда:
а) 1 өлешнең 1 пунктында «34 – 44» саннарын «34 – 43» саннарына алмаштырырга;
б) 2 өлешнең беренче абзацында «34 – 44» саннарын «34 – 43» саннарына алмаштырырга.

**2 статья**

Әлеге Закон 2026 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе

**«Татарстан Республикасы территориясендә салым салуның патент системасын кертү турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проектына**

**АҢЛАТМА**

«Татарстан Республикасы территориясендә салым салуның патент системасын кертү турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проекты (алга таба – закон проекты) Татарстан Республикасы законнарын федераль законнарга туры китерү максатларында эшләнде.

«Россия Федерациясе Салым кодексының икенче өлешендәге 346.43 статьясының 2 пунктындагы 44 пунктчасын үз көчен югалткан дип тану турында» 2025 елның 29 сентябрендәге 359-ФЗ номерлы Федераль закон белән салым салуның патент системасы кулланыла торган эшкуарлык эшчәнлеге төрләре исемлегеннән урам патрульләре, сакчылар, каравылчылар һәм вахтерлар хезмәтләре күрсәтү эшчәнлеге төшереп калдырыла.

Күрсәтелгән Федераль закон 2026 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

Шуңа бәйле рәвештә әлеге закон проектында «Татарстан Республикасы территориясендә салым салуның патент системасын кертү турында» 2012 елның 29 сентябрендәге 65-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына төгәлләштерә торган үзгәреш кертү каралган. Шулай ук үз көчен югалтуы таныла торган эшкуарлык эшчәнлеге төренә сылтамаларны төшереп калдыру максатыннан редакцион-техник характердагы үзгәрешләр кертелә.

Федераль салым хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе мәгълүматы буенча (5-Патент формасы) Татарстан Республикасында урам патрульләре, сакчылар, каравылчылар һәм вахтерлар хезмәтләре күрсәтүгә бәйле эшкуарлык эшчәнлеге төре буенча:

2024 ел йомгаклары буенча 66 индивидуаль эшкуарга 77 патент бирелгән;

2025 ел 1 яртыеллыгы йомгаклары буенча (2025 елның 1 июле торышы буенча) 38 индивидуаль эшкуарга 50 патент бирелгән.

---

**«Татарстан Республикасы территориясендә салым салуның патент системасын кертү турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итүгә бәйле рәвештә үз көчләрен югалткан дип танылырга, туктатылып торырга, үзгәрешләр кертелергә яки кабул ителергә тиешле Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлары**

**ИСЕМЛЕГЕ**

«Татарстан Республикасы территориясендә салым салуның патент системасын кертү турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы законнарын һәм башка норматив хокукый актларын үз көчләрен югалткан дип тануны, туктатып торуны, үзгәртүне яисә яңаларын кабул итүне таләп итми.

---

**«Татарстан Республикасы территориясендә салым салуның патент системасын кертү турында» Татарстан Ревспубликасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проектын**
**ФИНАНС-ИКЪТИСАДЫЙ НИГЕЗЛӘҮ**

«Татарстан Республикасы территориясендә салым салуның патент системасын кертү турында» Татарстан Ревспубликасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы бюджетыннан өстәмә акча бүлеп бирүне таләп итмәячәк.